| СОВЕТ<br>ЗВЕЗДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗВЕЗДА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Хорновар-Шигали

2 июня 2020 года № 64/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2017 елның 29 декабрендә кабул ителгән 455-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Советының 23.04.2012 ел, № 22/2 карары (26.10.2018 ел, № 43/3 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында:

**2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«2.1. Ачык тыңлаулар халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге башлыгы, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә.»;

**4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«4.1. Халык яисә авыл җирлеге Советы инициативасы белән үткәрелә торган ачык тыңлаулар авыл җирлеге Советы, ә авыл җирлеге башлыгы яисә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгы - авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Звезда авыл җирлеге башлыгы
Чүпрәле муниципаль районы М.В.Денисова